РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2020 елның 22 июле** **Чистай шәһәре** **№ 56/3**

Җирле әһәмияттәге
мәсьәләләрне хәл итү буенча
вәкаләтләрнең бер өлешен кабул
итү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен кабул итәргә:

- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты проектын төзү;
- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең расланган бюджетын үтәүне оештыру;
- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;
- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында хисап төзү.

2. Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Чистай шәһәр башкарма комитеты белән килешү төзергә, төзелә торган килешүнең гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дигән карарга килергә;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне билгеләнгән тәртиптә тапшыру турындагы килешүне имзалаганнан соң бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы башлыгы Д.А. Иванов